**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422711, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Альдермыш , ул. Хабибуллина, 25

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Әлдермеш авылы, Хабибуллина ур., 25

тел./факс 8(84365) 79-4-03 e-mail:Alder.Vsg@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**от 29 ноября 2018 года** **№ 137**

**2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 70 статьясы, “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Биектау районының территория сайлау комиссиясе 2018 елның 18 ноябрендә булган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлегенә 766 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 565, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның 73,76 процентын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Референдумда катнашучыларның 532 (94,16%) позициясе өчен тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; «НЕТ» позициясе өчен референдумда 33 катнашучы тавыш бирде, бу 5,84 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Әлдермеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә булган җирле референдумны узган дип, ә референдум нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2019 елда үзара салым чараларын Әлдермеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә һәм

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм Альдермыш авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;

Сая елгасы аша чыгу;

Өбрә балалар мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү” кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: http:/ vysokaya-gora.tatarstan.ru.

Совет председателе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Сабиров